**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«24» 05 2021 ел Яр Чаллы №1426

Торак урын мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының дәүләт торак программаларын тормышка ашыру максатында,

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатында, торак урынының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынының гомуми мәйданы 18 кв. метрдан да ким булмаган күләмдә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын бер гражданга торак урыны гомуми мәйданының 18 кв. метры күләмендә билгеләргә.

3. Тукай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясе нормативын исәпләү методикасын расларга (кушымта бирелә).

4. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак урыннары биргәндә һәм исәпкә куйганда мәйдан нормалары, гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясе нормативын исәпләү методикасы турында» 2013 елның 6 августындагы 4454 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү буенча урынбасары Р.С. Игътисамовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
№ 1426 от 24.05.12

**Тукай муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясе нормативын исәпләү методикасы**

Гомуми торак мәйданының 1 кв. м бәясе нормативы гомуми торак мәйданының 1 кв. метрына уртача базар бәясенә тигез күләмдә түбәндәге формула буенча билгеләнә :

РПС= ((Цп.р.+Цв.р.+СМ) х 0,92 + Сстр.): п4 х Кдефл. х Кг.м.,

биредә:

РПС – гомуми торак мәйданның 1 кв. метрына уртача базар бәясенең хисап күрсәткече;

Цп.р. – тиешле муниципаль берәмлектәге беренчел базарда типлаштырылган торакның Татарстанстат тарафыннан теркәлә торган уртача бәясе;

Цв.р. – тиешле муниципаль берәмлектәге икенчел базарда типлаштырылган торакның Татарстанстат тарафыннан теркәлә торган уртача бәясе;

СМ – хисап чорына кадәрге хисап чоры датасына гомуми торак мәйданының Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының Татарстан Республикасы буенча боерыгы белән билгеләнә торган (Россия Федерациясе төбәкләре буенча базар бәясенең мониторингы) 1 кв. метры бәясе;

Сстр. – тиешле муниципаль берәмлектә типлаштырылган торак төзелешенең Татарстанстат тарафыннан теркәлә торган бәясе;

п4 – исәпләгәндә кулланылган типик торак бәяләре күрсәткечләре саны (Цп.р., Цв.р.СМ, Сстр);

Кдефл. – фаразланган коэффициент – дефлятор.

«0,92» – сатып алучының риелторлар, нотариуслар, дәүләт пошлиналары хезмәтләре һәм күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуга бәйле башка чыгымнар өчен түләүгә юнәлдерелгән чыгымнары өлешен исәпкә ала торган коэффициент;

Кг.м. – сатып алучының риелторлар, нотариуслар, дәүләт пошлиналары хезмәтләре һәм күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуга бәйле башка чыгымнар өчен түләүгә юнәлдерелгән чыгымнары өлешен исәпкә ала торган коэффициент, ул тигез Ск: Сер. По РТ, биредә Ск – Казанда һәм Яр Чаллыда уртача базар бәясе, Сер. По РТ – хисап чорына кадәрге хисап чоры датасына Татарстан Республикасы буенча Татарстанстат тарафыннан билгеләнә торган уртача

базар. Башка муниципаль берәмлекләр өчен әлеге коэффициент исәпләнми һәм 1 гә тигез,

x – математик тапкырлау; : – математик бүлү.